ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 88-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 88-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәмммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 320-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 28 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«өч яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларны исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган дарулар белән түләүсез тәэмин итү;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач үз көченә керә.

2. Алты яшькә кадәрге бала өчен дарулар сатып алуга субсидия әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән гражданнар йә субсидия билгеләү срогы тәмамланганга кадәр әлеге субсидияне түләүгә йә, әлеге субсидияне алудан баш тарткан очракта, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 пунктының икенче абзацында (әлеге Закон редакциясендә) каралган социаль ярдәм чарасына хокуклы була.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы белән (алга таба - Указ) Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затларына күпбалалы гаиләләрдән булган 6 яшькә кадәрге балаларны дарулар белән түләүсез тәэмин итүне оештыру тәкъдим ителде.

Күрсәтелгән категориядәге балаларны ташламалы дарулар белән тәэмин итү шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина сәнәгатен үстерүгә һәм халыкны һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрен дарулар һәм медицина эшләнмәләре белән тәэмин итүне яхшыртуга дәүләт ярдәме турында» 1994 елның 30 июлендәге 890 номерлы карары карары нигезендә дә билгеләнгән.

Хәзерге вакытта «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 гыйнварындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән өч яшькә кадәрге барлык балалар да Татарстан Республикасы бюджетында регионда ташламалардан файдаланучыларны дарулар белән тәэмин итү өчен каралган акчалар кысаларында исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган дарулар белән түләүсез тәэмин ителә.

Күпбалалы гаиләләрдән булган 6 яшькә кадәрге балаларга дарулар алуга субсидия билгеләнгән.

Югарыда аталган Указны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы законы проекты белән гаилә составында, тәрбиягә алынганнарын да кертеп, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга, өлкән бала 18 яшькә җиткәнче яисә ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге формада белем алган очракта, 23 яшькә җиткәнче, 3 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларны исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган дарулар белән түләүсез тәэмин итү хокукын билгеләү күздә тотыла.

Алты яшькә кадәрге бала өчен дарулар сатып алуга субсидия тәкъдим ителә торган үзгәрешләр үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән гражданнарга күрсәтелгән субсидияне ул билгеләнгән срок тәмамланганчы алу, яисә, аны алудан баш тарткан очракта, дарулар белән түләүсез тәэмин ителү хокукы бирелә.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Татарстан Республикасында 2024 ел башына 0 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балалар саны 245 856 булган, шул исәптән 131 816 бала (53,6%) - 3 яшьтән алып 5 яшькә кадәргеләр (2025 елның 1 гыйнварына Дәүләт статистикасы федераль хезмәтендә (Росстат) мәгълүматлар юк).

2025 елда дарулар сатып алуга субсидия алучыларның фаразлана торган саны - күпбалалы гаиләләрдән булган 53 691 бала, бу 0 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларның гомуми санынннан 21,8% тәшкил итә.

Дару препаратлары сатып алуга субсидия алучы бары тик күпбалалы гаиләләрдән булган 0 яшьтән 5 яшькә кадәрге балаларга ташламалы дарулар бирүнең якынча фаразланган суммасы – елына 36,4 млн. сум.

Күпбалалы гаиләләрдән булган балаларга дарулар сатып алуга субсидия бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының елына 110,17 млн сум тәшкил итүен исәпкә алсак, закон проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча таләп ителмәячәк.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.